СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-60, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**15 август, 2024 ел** **№ 430**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының вакантлы идарә итү вазыйфаларын һәм иң югары һәм баш төркемнәренә караган вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 31 мартындагы 349 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы прокуратурасының гамәлдәге муниципаль норматив хокукый базага үзгәрешләр кертүне таләп итә торган федераль законнарга үзгәрешләр турындагы мәгълүматы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 349 номерлы карары (22.05.2020 № 373 карары редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының вакантлы идарә итү вазыйфаларын һәм иң югары һәм баш төркемнәренә караган вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 17 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы тарафыннан дәүләт органына тапшырылырга тиешле анкета формасын раслау турында» 2005 елның 26 маендагы 667-р күрсәтмәсе белән расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;»;

1.2. Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының вакантлы идарә итү вазыйфаларын һәм иң югары һәм баш төркемнәренә караган вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында нигезләмәгә 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә һәм Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов